# ТАТАР ТЕЛЕН САКЛАУ ҺӘМ ҮСТЕРҮ

**«ТатарчаМ» - ЯШЬЛӘР ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘМ ПРАКТИКАСЫН АРТТЫРУ ӨЧЕН МОБИЛЬ КУШЫМТАЛАР (ПРИЛОЖЕНИЕ).**

**АВТОР:** НИГЪМӘТУЛЛИНА ЗӘЙНӘП АЛМАЗ КЫЗЫ,
10 НЧЫ СЫЙНЫФ УКУЧЫСЫ
**ҖИТӘКЧЕ:** НУРГАЛИЕВА РЕЗЕДӘ РИФАТ КЫЗЫ,
ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫ.

**Проблема:** Яшьләр арасында татар телендә иркен сөйләшү сәләтенең начар үсеше. Теорияне белудә һәм сөйләмдә куллану арасындагы аерма.

**Мобиль кушымталар ярдәмендә чишү юлы**:

- Сүзлек/фразеологизмнар: тематик төркемнәргә бүленгән сөйләм телендә кулланыла торган сүзләр һәм аңлатмалар.
- Диалоглар (сценарийләр): реаль тормыш ситуацияләрендә: ресторанда, дуслар белән очрашуда, телефонда сөйләшүдә һ.б.
- Аватарлар/ботлар белән сөйләшү: ясалма интеллект ярдәмендә интерактив диалоглар. Пользователь җөмлә яза, ә бот татарча аңлый һәм табигый җавап кайтара.
- Биремнәр һәм уеннар: «Сөйләмдә җөмлә төзү», «Сүзләрне дөрес әйтү» «Татарча сүзләр табу» кебек максатчан биремнәр.
- Аудиоязмаларны кабул итү: пользователь үз тавышын яздыра, ә система аны татар телендә дөрес әйтү буенча анализлый.

**Статистика:** керү саны, өйрәнгән сүзләр, алган баллар турында мәгълүмат.

**Аудитория:** 14-25 яшьтәге татар телен башлангыч дәрәҗәдә белгән яшьләр.

**Өстенлекләре:** ирекле вакытта куллану мөмкинлеге, уен форматы, сөйләм практикасын үстерүгә ярдәм итү.

**Оештыру этаплары:** идеяләр туплау, анкета төзү , аудиторияне сынау, күзәтүләр, диаграмма төзү .

**Өмет иткән нәтиҗәләр:** яшьләр арасында татар телендә сөйләм практикасын арттыру, татарча сөйләшүдән оялуны киметү, телне «үле тел» статусыннан саклап калу.

# НИГӘ ЯШЬЛӘР ТАТАРЧА СӨЙЛӘШҮДӘН КУРКА?




- *Формаль белем*. Мәктәптә татар теле дәресләре кагыйдәләр, биремнәр һәм күнегүләр рәвешендә генә өйрәтелә. Дәрестә һәр хата түбән билге белән билгеләнә. Бу укучыларның мотивациясен, татар теле белән кызыксынуын киметә.
- *Социаль бүленеш*. Көндәлек тормышта татар теле кулланылмый: эштә, интернетта, дуслар арасында – рус теле өстенлек ала.
- *Психологик киртә*. «Сүзләрне, авазларны дөрес әйтмим», «Акцент белән сөйләшәм», «Үз фикеремне дөрес җиткермим», «Сүз байлыгы җитми, татарча сүзләрне җитәрлек белмим» кебек уйлар сөйләмнән туктата.


# «ЯБЫК ЦИКЛ» ҺӘМ НӘТИҖӘ

Мәктәп → Социаль мөхит → Психология → Технологияләр

→ Яшьләр кулланмый → "Үле тел" имиджы

- Тел кулланылмагач, "үле тел" образын ала.
- Бу образ яшьләрнең телне өйрәнүләренә түбән мотивация бирә.
- Нәтиҗәдә татар теле бары тик дәреслекләрдә генә кала, көндәлек сөйләмдә аз кулланыла яки бөтенләй кулланылмый.


# «CHAMALA» КУШЫМТАСЫ

















Бу кушымтада татар телен өйрәнү өчен яраклы күп кенә бүлекләр бар, мәсәлән, бот белән сөйләшү, аерым сүзләр белән карточкалар, фразалар җыярга өйрәнү һ. б

# «ТАТАРЧА ФИЛВОРД» КУШЫМТАСЫ




Татар сүзләрен эзләү уены татар телендә актив лексиканы күнектерү, яңа сүзләр өйрәнү, уйнап тел байлыгын үстерү, яшьләр һәм балалар өчен кызыклы форматтагы уен булып тора.
















# «ЯНДЕКС ПЕРЕВОДЧИК» КУШЫМТАСЫ




Кушымтаның бу өлешендә әңгәмәдәш белән аның интонациясен ишетү һәм сөйләшү тизрәк бару өчен әңгәмә корырга һәм башка функцияләрен дә кулланырга мөмкин →












Кушымтаның бу өлешендә текстны бастырырга, үз фикереңне төгәлрәк формалаштырырга һәм әңгәмәдәшеңә күрсәтергә мөмкин

# АНКЕТА ҮТҮЧЕЛӘР АРАСЫНДА ЯКЫНЧА СТАТИСТИКА




Анкетага сылтама: https://disk.yandex.ru/i/YMFKOtgeWcj02g

# ПРОЕКТНЫҢ ФАЙДАЛЫ ҺӘМ ҮСТЕНЛЕКЛЕ ЯКЛАРЫ

- Психологик файда: куркуны киметә, сөйләшүгә ышаныч тудыра, ышаныч арта.
- Методик файда: теориядән практикага күчерә, хәтерне яхшырта.
- Технологик файда: татар телендә сөйләшү практикасы яшьләрнең төп мәйданына керә, мобиль кушымталар актив кулланыла башлый, татар телен саклау һәм үстерү проблемасын системалы рәвештә (психология + технология + методика) чишә.

# ЙОМГАКЛАУ



*Сүз - бер көнлек, тел - гомерлек.*

Безнең проблема – телне белү-белмәүдә түгел, ә кулланырга куркуда, батырчылык итмәүдә.

"ТатарчаМ" проекты бу психологик куркуны бетерү, социаль бушлыкны тутыру һәм технологик киртәне бетерү юнәлешендә башлангыч адым.